Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте

Россия мөфтиләр Шурасы

بسم الله الرحمن الرحيم

# Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия мөфтиләр шурасы рәисе мөфти шәех Равил Гайнетдиннең Гыйд әл-Фитр — Ураза гаете уңаеннан мөрәҗәгатьнамәсе

**Мәскәү**
Һиҗри 1440 елның 1нче шәүвәле
Милади 2019 елның 4нче июне

## БИСМИЛЛЯХИР-
## РАХМАНИР-РАХИМ!

Рәхмәтле вә Рәхимле Аллаһу Тәгалә
исеме белән башлыйм!

Бар нәрсәгә Үзенең чиксез шәфәгате җиткән, Үзенең исәпсез-хисапсыз байлыклары белән бүләкләгән һәм мөселманнарыбыз йөрәге ихлас инану вә тәкъвалык белән тулган изге Рамазанда безгә фарыз булган уразаны тиешенчә тотып чыгарга булышкан Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгаләгә чиксез мактауларыбыз булса иде! Безләргә уразаны ничек итеп тотарга икәнлеген өйрәтеп калдырган һәм өммәтен Раббыбызның мәгъфирәте — гөнаһларның гафу ителүе белән сөендергән, галәмгә рәхмәт өчен җибәрелгән соңгы Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа ﷺ гә Аллаһының сәламе булсын! Хөрмәтле дин кардәшләрем, барчаларыгызга да Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгаләнең рәхмәте вә бәрәкәте булсын!

Бүген без Рамазан уразасын тәмамлап, өммәтебезнең якты, иң зур бәйрәме — Гайдел Фитр — Ураза гаетенә җыелдык. Бүген дөньяның барча мөселманнары чиксез шатлык хисләре кичерә. Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгалә каршындагы бурычны үтәп чыгу шатлыгы, нәфесебезгә хуҗа булуга, инануларыбыз, иманнарыбыз ныклыгына сынауны үтә алуыбызга сөенәбез. Көтеп алынган шушы бәйрәм көнне барчаларыгызның шатлыгы уңаеннан Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия мөфтиләр Шурасы һәм шәхсән үз исемемнән һәммәгезне Ураза гаете белән чын күңелдән котлыйм. Кәламе Шәрифтә бу хакта:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

«Ий, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кеби, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз!» (Коръәни Кәрим, 2:183)

Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгаләдән тоткан уразаларыбызның, укыган намазларыбызның, кылган догаларыбызның кабуллыгын сорыйбыз. Һәм киләсе Рамазанны да исән-сау каршылап, киләчәк тормышыбызда яшәү кагыйдәләре булып торган рухи-әхлакый кыйммәтләргә төшенү, һәрьяклы камилләшү насыйп булса иде дип телибез. Һәм Раббыбыз Аллаһу Тәгалә безләрне киләчәктә дә чиксез рәхмәтеннән ташламавын, гөнаһларыбызны ярлыкавын сорыйбыз.

Ел буе сагынып көтеп алган Рамазан ае сизелми үтеп тә китте. Изге Рамазаныбыз төгәлләнү һәм аның белән хушлашу йөрәкләребездә кабаттан сагыну хисләре уятты. Ураза тотуның никадәрле дә зур гыйбадәт булуын, аның асылын һәм әҗер-савабын моңа ихластан ышанучылар гына аңлый.

Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгаләгә барча мактауларыбыз булсын! Рамазанның һәр көнен безгә бирелгән бүләк дип кабул иткән хәлдә күбрәк изгелекләр кылырга омтылып, өйләребездә һәм мәчетләрдә намазларыбызны укып тоттык уразаларыбызны, изге китабыбыз Коръәни Кәримне укыдык вә хикмәтле гыйлем алдык. Шатланып әҗер-саваплы гамәлләр башкардык, сәдакаларыбыз белән авыруларга һәм мохтаҗларга ярдәм итәргә тырыштык. Изгелек кылу, тирә-яктагыларга рәхим-шәфкатьлелек күрсәтүләр аша үзебездә мәрхәмәтле булу, ярдәмчеллек һәм тыйнаклык сыйфатларын тәрбияләргә омтылдык.

Рамазан ае буена күркәм холыкка омтылып, акылыбыз, рухыбыз, тәнебез һәм теләкләребез белән бер Аллаһы Тәгаләгә буйсынып, күпләребез рухи һәм физик яктан ныгыдык. Рухи-әхлакый яктан камилләшеп, Галәмнәр Хуҗасының әмерен үтәргә омтылдык.

قَدْ أَفْلَحَ مَن تَزَكَّى وَذَكَرَ اسْمَ رَبِّهِ فَصَلَّى

«Мөшриклектән вә монафикълыктан, рия вә бидгать гамәлләрдән, фәхеш вә хәрам эшләрдән үзен пакъләгән һәм сакланган кеше, тәхкыйк гәзабтан котылып, өстенлек тапты. Вә ул кеше Раббысына зикер итеп намаз укыды». (Коръәни Кәрим, 87:14-15)

Шул ук вакытта Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең түбәндәге сүзләрен истән чыгармадык:

مَنْ صَامَ رَمَضَانَ إِيمَانًا وَاحْتِسَابًا غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ

«Рамазанда Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ышанып һәм ихластан өмет итеп ураза тотучының элеккеге гөнаһлары да кичерелер, гафу кылыныр» («Сәхих», Әл-Бохари).

Ай буена күңелләребез нечкәргән хәлдә гыйбадәттә булдык, ашау-эчүдән тыелып кына түгел, гөнаһлы адымнардан, гайбәттән, ямьсез сүзләрдән тыелдык. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен тоттык уразаларыбызны. Фәкать Аның рәхмәтенә, шәфәгатенә һәм гөнаһларыбызны кичерелүенә өметләндек. Гади булмаган әлеге сынауны үтәп чыга алуыбызда Аллаһы Сүбханәһү вә Тәгаләгә рәхмәтлебез. Ай буена нәфесебезгә, теләкләребезгә хуҗа булып, уразада вакытта аның рухи ягына өстенлек биреп, нәфесебез белән итәргә. ю тыела белергә дә көчебездән килүен расладык. Ашау-эчүдән тыелуга караганда, телне, күңелне ямьсез уйлардан тыю күпкә авыр булуын аңладык. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйткән:

مَنْ لَمْ يَدَعْ قَوْلَ الزُّورِ وَالْعَمَلَ بِهِ وَالْجَهْلَ فَلَيْسَ لِلَّهِ حَاجَةٌ فِي أَنْ يَدَعَ طَعَامَهُ وَشَرَابَهُ

«Алдауларын, ялганлауларын, ямьсез гамәлләр башкаруларын дәвам итүчеләрнең ашау-эчүдән тыелуларына Аллаһу Тәгалә мохтаҗ түгел». («Сәхих», Әл-Бохари)

Бүген һәрберебез «Бу айда Раббыма якыная алдыммы?», «Үземдә юмартлык, киң күңеллелек сыйфатлары тәрбияли алдыммы?», «Тирә-ягымдагыларга игелек-шәфкать кылдыммы?», һәм иң мөһиме «Үземне үзгәртә алдыммы?» дип, уразасына нәтиҗә чыгарырга тиеш. Үз-үзебезгә шушы сорауларны куеп кына без Рамазанны Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтле, олуг ае дип кенә түгел, ә тирә-ягындагыларга карата кешелеклелек, гаделлек, игелек-шәфкать күрсәтү ае булуына төшенәчәкбез; шәхси мәнфәгатьләрне калдырып торып, тирә-ягыбызга күз салсак, бигрәк тә авыр сынаулар алдында калучы, кайгы-хәсрәттә, ирексез яшәүче миллионнарны күреп, Рамазанның асыл әһәмиятен аңларбыз.

Әйе, Рамазан төгәлләнде. Әмма шунысын истә тотыйк: Рамазаннан соң да тормыш дәвам итә, барча кылганыбыз Гамәл дәфтәребезгә языла тора. Эш-гамәлләребез язылган бу Гамәл дәфтәребез белән Аллаһы Тәгалә каршысына барачакбыз. Рамазанда тәрбияләгән күңел чисталыгын, миһербан-шәфкатьлелекне, күркәм холыкны киләчәктә дә саклыйк! Моннан соң да һәркайсыбызның хәер-догаларыбыз белән, сүзе һәм эше белән, мал-мөлкәте белән тирә-ягыбыздагы ярдәмгә аеруча мохтаҗларның хәленә кереп, ярдәм итүе бик әһәмиятле. Нәкъ менә ураза тоткан хәлдә без авыр тормышта тилмереп яшәгән, матди кыенлыклар кичерүченең хәлен, күңел халәтен аңларбыз.

Ураза тотканда рухи көчебезне, Аллаһ әмеренә тугрылыгыбызны сынау авыр булып тоелса да, иманыбыз, күңелебез, рухи пакълыгыбыз өчен бу сынаулар файдага гына булды. Арабызда

Коръәндә һәм Пәйгамбәребез ﷺ сөннәтендә тәгаенләнгән сәбәпләр аркасында уразасын тота алмаучылар да бардыр. Динебез берәүгә дә көченнән килмәгәнне йөкләми, авырлык китермәгән җиңел дин. Аллаһу Сүбханә вә Тәгалә динебездә безнең өчен бернинди кыенлыклар тудырмаган. Саулыгы-сәламәтлеге булган, хәле җиткән һәркемгә ураза тоту фарыз ителсә дә, төрле сәбәпләр аркасында бу гыйбадәтне үтәргә мөмкинлеге булмаучыларның да хәленә кереп, уразасы калган көннәрне ахырдан тоту, яки кайбер очракларда фидия сәдакасы биреп, уразаны өстеннән төшерү рөхсәт ителә.

Әлеге искәрмәләр Аллаһы Тәгаләнең инсаннарына чиксез рәхим-шәфкатен һәм динебезне тотуда җиңеллекләр бирүен күрсәтә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйтә:

إن الدين يسر ولن يشاد الدينَ إلا غلبه

«Чынлыкта дин тоту җиңел. Әмма кем дә булса дингә каршы көрәшә башласа, һичшиксез динебез өстен чыгачак». («Сәхих», Әл-Бохари)

Рамазан уразасы шулкадәр камил ки, ул мөселманның аерым шәхес буларак үсешен генә күздә тотмыйча, башкаларга хезмәт итү, ярдәм кулы сузу аша гыйбадәт кылуны да үз эченә сыйдырган. Бу тирә-ягындагыларга игелекләр эшләүдә, җылы сүз әйтеп игътибар күрсәтүдә, йортсыз-җирсезләргә, өлкәннәргә, ятимнәргә карата рухи һәм матди ярдәм күрсәтүдә чагыла. Гаеткә кадәр һәр мөселманның матди кереме нинди булуга карамастан, фитра сәдакасы бирергә тиешлеге дә моның дәлиле.

فَرَضَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ زَكَاةَ الْفِطْرِ طُهْرَةً لِلصَّائِمِ مِنَ اللَّغْوِ وَالرَّفَثِ، وَطُعْمَةً لِلْمَسَاكِينِ

«Аллаһ илчесе ﷺ ураза тотучыларга буш һәм кирәкмәгән сүзләреннән чистарыну чарасы булган зәкәт әл-фитраларын өләшергә һәм шул ук вакытта фәкыйрьләрне сыйларга боерды». («Сөнән», Әбү Дауд)

Бүген Ураза гаетенә килгәндә бөтен кеше ишетерлек итеп бәйрәм тәкбирләре әйттек, уразаларыбызны сау-сәламәт хәлләребездә һәм тыныч күңел белән башкарып чыгарган Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгаләгә олугларыбызны һәм мактауларыбызны җиткердек. Бу бәйрәм көннәрен туганнарыбызның хәлләрен белеп, әби-бабаларыбызны искә алып, бүләкләр бирешеп һәм Ватаныбызга тынычлык, иркен, имин тормышлар теләп, догалар кылып үткәрәбез. Аллаһу Сүбханәһү вә Тәгаләдән киләсе бәйрәмнәрне дә саулык-сәламәтлек белән каршылап, безләргә шушы динисламыбыз юлын сакларга, дәвам итәргә насыйп ит дип сорыйбыз. Аллаһу Тәгалә иманнарыбызны ныгытып, тирә-ягыбыздагыларга карата йөрәкләребездә рәхим-шәфкать, изгелек итү, игелек кылу хисләрен куәтләп, яхшылык, гаделлекләребезне арттырсын һәм Ватаныбызга һәм кешелек дөньясына тынычлыкта һәм иминлектә яшәргә язсын дип бөек Раббыбыздан сорыйм.

**Әс-саләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!**

***Мөфти шәех Равил Гайнетдин,***
*Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*Россия мөфтиләр шурасы рәисе,*
*Россия Федерациясе Президенты каршындагы Дини оешмалар белән хезмәттәшлек буенча Совет әгъзасы*